МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 598/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 16 » 05 2025 ел

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 28.12.2023 ел, №218/о боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 28.12.2023 ел, №218/о боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге боерыкның Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына карата 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган нигезләмәләреннән тыш, әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына карата 2027 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.»;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 28.12.2023 ел, №218/о боерыгы белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж.Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 28.12.2023 ел, №218/о боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 16.05.2025 ел, № 598/о боерыгы редакциясендә)

# Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.1. Мөрәҗәгать итүчеләр: җир кишәрлекләре милекчеләре булган физик һәм юридик затлар яки җир кишәрлекләренә ия булучылар һәм алардан даими (вакыты чикләнмәгән нигездә) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп биләү хокукында аренда шартнамәсе, субаренда шартнамәсе буенча файдаланучылар, шулай ук, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясындагы 1.1, 1.2 өлешләрендә каралган очракларда, башка затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче). Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен закон таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән законлы вәкилләр яисә затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) яклый ала.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән, гариза бирүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

1.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ) үзара хезмәттәшлек турында тиешле килешү булганда катнаша.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарлар КФҮ әлеге Регламентның 2.7 пункты таләпләре нигезендә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләре:

1) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы формасын һәм аны тутыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 25 апрелендәге 741/пр номерлы боерыгы белән расланган форма буенча җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы (алга таба – ГПЗУ);

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

ГПЗУ реквизитларында һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарларда түбәндәгеләр була:

теркәү номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

документны имзалауга вәкаләтле затның вазыйфасы;

документны имзалауга вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу факты шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Система) теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (алга таба – Республика порталы) (https://uslugi.tatarsta№.ru/) мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәкнең вәкаләтле хезмәткәренең мөһере һәм имзасы

белән таныкланган, кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә күпфункцияле үзәктән дә алына ала.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен Министрлыкта, КФҮ аша электрон документ яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

1.1.Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты:

1) гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетта күренә торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы беркетелгән көннән соң 14 эш көне дәвамында күрсәтелә.

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша бирелгән очракта, гариза һәм документлар КФҮ теркәлгән көннән алып дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан 14 эш көне эчендә, шулай ук КФҮ регламентында каралган срокны исәпкә алып, күрсәтелә.

3) гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән Министрлыкка тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Министрлыкта теркәлгән көннән алып 14 эш көне эчендә күрсәтелә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Системадан файдаланып (техник мөмкинлек булганда) бирелгән очракта, дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Министрлыкта теркәлгән көннән алып 14 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ рәвешендә җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны кәгазьдә бирү мөрәҗәгать итүче нәтиҗә бирүне сорап мөрәҗәгать иткән көнне, әмма дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көннән дә иртәрәк булмаган чорда гамәлгә ашырыла.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлыкның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турында гариза:

КФҮ яисә турыдан-туры Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең үз кулы белән яисә мөрәҗәгать итүченең вәкиле тарафыннан имзаланган кәгазь формада (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүченең яки ул вәкаләт биргән затның гади электрон имзасы белән имзаланган, Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетын кулланып, электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла);

2) шәхесне таныклый торган документ (КФҮ мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелә). Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә;

3) мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итәргә вәкаләтләрен раслый торган документ (хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта).

Документлар Бердәм портал, Республика порталы аша электрон рәвештә тапшырылган очракта, юридик зат булып торучы мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән күрсәтелгән документ мондый юридик затның хокуклы вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы яисә көчәйтелгән квалификациясез электрон имзасы белән, ә физик зат булып торучы мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документ көчәйтелгән нотариусның квалификацияле электрон имзасы белән имзалана;

4) аңа карата хокуклар Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән җир кишәрлегенә карата хокук билгеләүче документлар.

2.6.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) КФҮ һәм Министрлык арасындагы үзара хезмәттәшлек турында Килешүгә ярашлы рәвештә КФҮ аша кәгазь формада;

2) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә шәхси мөрәҗәгать яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша турыдан-туры Министрлыкка кәгазьдә тапшырыла;

3) Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Системадан (техник мөмкинлекләр булганда) файдаланып, электрон формада.

2.6.3. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризага теркәп тапшырыла торган документларның күчермәләре нотариаль расланырга мөмкин. Нотариаль таныкланган күчермәләр булмаганда, тигез дәрәҗәдә түбәндәгеләр кабул ителергә тиеш:

дөреслеге җитәкченең яки моңа вәкаләт бирелгән вазыйфаи затның имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән таныкланган документларның күчермәләре;

документның төп нөсхәсен күрсәтү шарты белән, таныкланмаган күчермәләр. Шул ук вакытта документның күчермәсе документларны кабул итүче зат тарафыннан төп нөсхәсе белән чагыштырыла.

2.6.4. Гариза Бердәм портал, Республика порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БМАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең электрон документ рәвешендәге (электрон документ үрнәге) ышаныч кәгазе мондый документларны ясауга һәм имзалауга вәкаләтле булган затларның, шул исәптән нотариусның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныклана.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, p№g, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан түбәндәге документлар (аларның күчермәләре яисә алардагы белешмәләр) соратып алынырга мөмкин:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

2) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

3) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр (күчемсез мөлкәт объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә ала). Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан

Республикасы буенча идарәсенә җибәрелә;

4) капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә (электр белән тәэмин итү челтәрләреннән тыш) тоташтыру (технологик тоташтыру)мөмкинлеге турында мәгълүмат, ул җирлек, муниципаль округ, шәһәр округы коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын исәпкә алып билгеләнә (алар булган очракта), аның составына мондый челтәрләргә тоташу (технологик тоташтыру) мөмкин булган нокталарында максималь йөкләнеш турында белешмәләр, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясындагы 7 өлешендә билгеләнгән тәртиптә инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүче оешмалардан әлеге мәгълүматны тапшырган оешма турында белешмәләр керә;

5) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта территорияне ызанлауның расланган проекты һәм (яисә) җир кишәрлегенең яисә җир кишәрлекләренең территориянең кадастр планында урнашу схемасы; Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән территориянең кадастр планы;

6) җир кишәрлегеннән файдалануны чикләүләр турында мәгълүмат, шул исәптән җир кишәрлеге тулысынча яисә өлешчә файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә урнашкан булса, - Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органына;

7) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре турында мәгълүмат, шул исәптән җир кишәрлеге тулысынча яисә өлешчә шундый зоналар чикләрендә урнашкан булса, - Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органына.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә дә тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турында гариза хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына тапшырылса;

2) гариза рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес тутырмау;

3) әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктчасында каралган документларны тапшырмау (документларның тулы булмаган комплектын тапшыру);

4) тапшырылган документлар хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көнгә үз көчен югалткан булса (шәхесне таныклаучы документ; мөрәҗәгать итүче вәкиле вәкаләтләрен таныклаучы документ);

5) тапшырылган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган текстны чистарту һәм төзәтүләр булса;

6) электрон рәвештә тапшырылган документларда зарарланган урыннар була, аларның булуы документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә алырга мөмкинлек бирмәсә;

7) электрон рәвештә тапшырылган документларда 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаны дөрес дип тану шартларының үтәлмәве ачыкланса.

2.7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, шушы Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетка җибәрелә яисә күрсәтелгән карарны алу өчен КФҮ яисә Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

1.1.1. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турында гариза, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^{3}$ статьясындагы 1.1, 1.2 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, җир кишәрлегенә хокук иясе булмаган зат тарафыннан бирелгән булса;

2) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру мондый документлар булмаганда рөхсәт ителмәгән очракта, территорияне планлаштыру буенча расланган документациянең булмавы;

Бу очракта территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә карата ГПЗУ бирү территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру документлары булганда гына рөхсәт ителә (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яки муниципаль берәмлек тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карарны мөстәкыйль гамәлгә ашыру яисә мондый карарны Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты тарафыннан шәһәр төзелеше кодексы

нигезендә билгеләнгән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашыру очракларыннан тыш);

3) җир кишәрлегенең чикләре, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^3$ статьясындагы 1.1, 1.2 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә билгеләнмәгән булса.

1.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, шушы Регламентның 4 нче кушымтасында билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә һәм билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда, мөрәҗәгать итүче турыдан-туры дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

1.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү вакыты.

1.1.1. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза вазыйфаи инструкция нигезендә гариза гаризаны кабул итү һәм теркәүне гамәлгә ашыручы күпфункцияле үзәк хезмәткәре (алга таба – КФҮ хезмәткәре) тарафыннан алынган көнендә теркәлә.

Гаризаны һәм теркәлә торган документларны Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Министрлыкка тапшыру тәэмин ителә.

Күпфункцияле үзәк аша килгән гариза һәм теркәлә торган документлар Министрлыкта алынган көнендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

1.1.1. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы, Система аша (техник мөмкинлек булганда) турыдан-туры Министрлыкка кәгазьдә җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталның, Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелгәнлеген раслаучы хәбәр ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән була.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, биналардан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның бинадан, бүлмәләрдән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә сукырларны озата йөри торган этне кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү;

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

1.1.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бинаны һәм биналарны инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына киртәсез керү мөмкинлеген булдыручы чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүче башка шартларны үтәү;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә Бердәм портал, Республика порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Министрлык хезмәткәрләренең Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның вазыйфаи затлары белән үзара бәйләнешкә керү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

барлык кирәкле документлар белән гариза тапшырылганда, – бер тапкыр;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара бәйләнешкә керү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче кучмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, күпфункцияле үзәктән алынырга мөмкин.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

1.1.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

1.1.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

1.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

1.1.1. Министрлыкның рәсми сайтында, дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарындагы стендларда һәм күпфункцияле үзәктә түбәндәге белешмә мәгълүмат урнаштырыла:

вәкаләтле органның һәм аларның дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең урнашу урыны һәм эш графигы турында;

вәкаләтле органның дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү өчен җаваплы структур бүлекчәләренең белешмә телефоннары, шул исәптән телефон-автоинформатор номеры (булган очракта);

«Интернет» челтәрендәге рәсми сайтның, шулай ук вәкаләтле органның электрон почтасының һәм (яисә) кире элемтә рәвешенең адресы.

1.1.1. Елга бер мәртәбә Бердәм порталда һәм Республика порталында күрсәтелә торган дәүләт хезмәте клиентларның ихтыяҗларына туры килү-килмәве буенча тикшерелә һәм, кирәк булганда, реинжинирингка җибәрелә.

1.1.1. Дәүләт (муниципаль) хезмәте күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән Административ регламент урнаштырыла:

Министрлыкның һәм КФҮ көтү залларында, әлеге норматив хокукый актлар мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә;

Министрлыкның рәсми сайтында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинеттан, КФҮ аша алынырга мөмкин.

1. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

1.1.Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү варианты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм булдырылган реестр язуларында җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

1.1. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау.

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә;

2) мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

1.1.Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

1.1.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә – Министрлыкның территорияләрне үстерү департаментының җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү мәгълүмат системасы бүлеге белгече (алга таба – Бүлек).

1.1.1. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап, күпфункцияле үзәккә шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮ https://mfc.tatarstaNo.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

1.1.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән, телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, Министрлык сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

1.1. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны шәхсән яисә ышанычлы заты аша турыдан-туры Министрлыкка, Бердәм портал, Республика порталы, Система (техник мөмкинлек булганда) яисә КФҮ аша бирә ала.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны КФҮ аша кабул итү.

1.1.1.1.Мөрәҗәгать итүче шәхсән (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) дәүләт

хезмәте күрсәтү турында гариза белән КФҮ мөрәҗәгать итә һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документлар тапшыра.

1.1.1.1.Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган хезмәткәре күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра. Гаризага «Гариза теркәлде» статусы бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрү өчен әзер гариза һәм документлар пакеты.

1.1.1.1. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче КФҮ регламентында каралган сроклар дәвамында КФҮ структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көненнән соңга калмыйча Министрлыкка тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Бердәм портал, Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

1) авторизация уза;

2) электрон гариза формасын ача;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

4) электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

5) электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

6) хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

7) тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

8) электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана;

9) электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

1.1.1.1. Гаризага «Гариза теркәлде» статусы бирелә. Техник мөмкинлек булганда, статус бирү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә җибәрелгән электрон эш.

1.1.1. Министрлыкка КФҮ яисә Бердәм портал, Республика порталы, система аша җибәрелгән гаризаны һәм документлар пакетын (электрон эшне) карау (техник мөмкинлекләр булганда). Министрлыкка кергәндә гаризага автомат рәвештә «Документларны тикшерү» статусы бирелә, бу Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетта чагылдырыла.

1.1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның Министрлыкка алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат – Министрлык белгече.

1.1.1.1.Документлар карауга алынганнан соң Министрлыкның вазыйфаи заты:

1) алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

2) документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

3) Бердәм порталга, Республика порталына керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Әлеге Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әлеге Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартларының үтәлмәве ачыкланса, баш тарту турындагы карар проектында аны кабул итү өчен нигез булган 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясындагы пунктлары булырга тиеш.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар проекты, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетка, шулай ук мөрәҗәгать итүченең карары буенча, КФҮ, Министрлык аша шәхсән алынырга мөмкин.

1.1.1.1.Әлеге Регламентның 3.5.3.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

1.1.1.1.Әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен алынган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гаризаны карау өчен кабул итү яки дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү.

1.1.1. Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы ведомствоара мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне юллау өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып министрлык белгече тора.

1.1.1. Министрлык белгече әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм, электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураларны нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

1.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен сорала торган документлар исемлеге шушы Регламентның 2.6.5 пунктында китерелгән.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

1.1.1. Әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гарызнамәне юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

1.1.1. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән (ике эш көне –дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алганда) артмаска тиеш.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

1.1.1. Министрлык белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча мәгълүмат алынган көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Министрлыкка җибәрелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаган очракта, баш тарту турында белдерү.

1.1.1. Әлеге Регламентның 3.6 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Министрлык белгеченә гариза һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган белешмәләр килү административ процедураны гамәлгә ашыруа башлауның нигезе булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Министрлык белгече тора.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләгәндә Бүлек белгече түбәндәге вариантлар буенча административ гамәлләр башкара:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен шушы Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланганда, гаризага «Баш тарту турында хат әзерләү» статусын бирә, баш тарту сәбәпләрен әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән форма буенча күрсәтеп, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проекты Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана. Имзаланганнан соң гаризага

«Баш тарту әзерләнде» статусы бирелә;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре буенча ГПЗУ проектын әзерли, гаризага «Документны әзерләү» статусын бирә; ГПЗУ проекты көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана. Имзаланганнан соң гаризага «Нәтиҗә әзерләнде» статусы бирелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән административ процедуралар ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән документлар (белешмәләр) алынган көннән алып биш эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: ГПЗУ яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар.

1.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи затның дәүләт хезмәте күрсәтелүен (ГПЗУ бирүдән баш тарту) раслый торган документны алуы административ процедураны гамәлгә ашыра башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып Министрлык белгече тора.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (ГПЗУ бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көнне гамәлгә ашырыла.

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе.

1.1.1.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбенә карап, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән аңа, алынмалы-куелмалы саклагыч җайланмага яздыру юлы белән, электрон документ нөсхәсе дә бирелә ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче КФҮ килгән көнне КФҮ эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документ (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар) бирү.

1.1.1.1.Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның Министрлыкның вәкаләтле

вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне (ГПЗУ бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документны җибәрү (тапшыру) (шул исәптән ГПЗУ бирүдән баш тарту).

1.1.1.1.Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен сорап Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, Министрлыкның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка килгән көнне, Министрлыкның эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне раслый торган документ (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар) бирү.

1.1. Техник хатаны төзәтү (техник хатаны төзәтүдән баш тарту).

1.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка Бердәм портал, Республика порталы яисә КФҮ аша түбәндәге документларны җибәрә:

шәхесне таныклый торган документ (күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелә); Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, шәхесне таныклый торган документтагы белешмәләр ИАБС системасында исәпкә алу язуын раслаган вакытта тикшерелә;

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

1.1.1. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән гаризаны терки һәм аларны документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

1.1.1. Техник хатаны төзәтүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче техник хатаны төзәтергә вәкаләтләре булмаган органга мөрәҗәгать итсә;

гаризада күрсәтелгән ГПЗУ реквизитлары ГПЗУ идентификацияләргә мөмкинлек бирмәсә;

мөрәҗәгать итүче ГПЗУ әзерләү өчен бирелгән гаризаның иясе булып тормаса һәм күрсәтелгән гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен хокук иясеннән тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләргә ия булмаса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^{3}$ статьясындагы 1.1, 1.2 өлешләрендә каралган очраклардан тыш;

техник хата булмаса.

1.1.1. Техник хатаны төзәтү (техник хатаны төзәтүдән баш тарту) процедурасын гамәлгә ашыру вакыты техник хатаны төзәтүгә гариза теркәлгән көннән алып 5 эш көне тәшкил итә.

1.1.1. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карый һәм түбәндәге вариантлар нигезендә административ гамәлләр башкара:

1) шушы Регламентның 3.9.3 пунктында күрсәтелгән техник хатаны төзәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, техник хатаны төзәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли (5 нче кушымта ), баш тарту сәбәпләрен күрсәтә, ул Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

2) шушы Регламентның 3.9.3 пунктында каралган техник хатаны төзәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, техник хатаны төзәтү өчен кирәкле документларны карау йомгаклары буенча төзәтелгән документны әзерли, аңа Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куела.

Имзаланган документның электрон рәвеше Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә. Мөрәҗәгать итүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең карары буенча КФҮ, Министрлык аша шәхсән үзенә имзалатып бирелә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Бүлек җитәкчесе тарафыннан

әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрү, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү, алар буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3.Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1[1] өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»

5.1. Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручы затка (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка) бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15' статьясында күрсәтелгән гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса.

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын, Бердәм порталны, Республика порталын кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта буенча, «Интернет» челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында да алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән

документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хataларны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача формада яки, аның ихтыярына карап, электрон формада шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу

үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.12. Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Рәвеше

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турында гариза

«__» __________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

1. Мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Физик зат мөрәҗәгать итүче булган очракта физик зат турында белешмәләр: | |
| 1.1.1 | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| 1.1.2 | Шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булган очракта күрсәтелми) | |
| 1.1.3 | Мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булган очракта, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры | |
| 1.2 | Мөрәҗәгать итүче юридик зат булган очракта, юридик зат турында белешмәләр: | |
| 1.2.1 | Тулы атамасы | |
| 1.2.2 | Төп дәүләт теркәве номеры | |
| 1.2.3 | Салым түләүче - юридик затның идентификация номеры | |

2. Җир кишәрлеге турында белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | |
| 2.2 | Территорияне ызанлауның расланган проектының һәм (яисә) барлыкка килә торган җир кишәрлегенең территориянең кадастр планында урнашу схемасының реквизитлары һәм барлыкка килә торган җир кишәрлегенең проект мәйданы (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^{3}$ статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта күрсәтелә) | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.3 | Җир кишәрлегеннән файдаланунық максаты | |
| 2.4 | Җир кишәрлегенең адресы яисә урнашу урыны тасвирламасы<br>(Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $57^{3}$ статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта күрсәтелә) | |

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирүегезне сорыйм.
Кушымта: ______________________________________________________________
Элемтә өчен телефон номеры һәм электрон почта адресы:
_____________________________________________________________________________.
Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен түбәндәгечә бирүегез турында үтенәм:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында/дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталында шәхси кабинетка электрон документ рәвешендә җибәреп. | |
| _______________________ адресы буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә. | |
| _____________________ адресы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә. | |
| ___________________ почта адресына кәгазь чыганакта җибәреп. | |
| Санап үтелгән ысулларның берсе күрсәтелә | |

______________ ________________________

(имза) (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы

1. Мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр

| | |
|---|---|
| Физик зат мөрәҗәгать итүче булган очракта физик зат турында белешмәләр: | |
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| Шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булган очракта күрсәтелми) | |
| Мөрәҗәгать итүче шәхси эшкуар булган очракта, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры | |
| Мөрәҗәгать итүче юридик зат булган очракта, юридик зат турында белешмәләр: | |
| Тулы атамасы | |
| Төп дәүләт теркәве номеры | |
| Салым түләүче – юридик затның идентификация номеры | |

2. Хатасы/ ялгышы булган, җир кишәрлегенең бирелгән шәһәр төзелеше планы турында белешмәләр

| Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын биргән орган | Документның номеры | Документның датасы |
|---|---|---|
| | | |

3. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планына төзәтмәләр кертү өчен нигезләү

| Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән күрсәткечләр (белешмәләр) | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планында күрсәтелергә тиешле мәгълүматлар (белешмәләр) | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турында карар кабул ителгән документның реквизитларын, документларын күрсәтеп нигезләү |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Хатасы/ялгышы булган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планына төзәтмәләр кертүегезне сорыйм.

Кушымта:

______________________________________________________________

Элемтә өчен телефон номеры һәм электрон почта адресы:

______________________________________________________________

Әлеге гаризаны карау нәтиҗәсен түбәндәгечә бирүегезне үтенәм:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында/дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталында шәхси кабинетка электрон документ рәвешендә җибәреп. | |
| ___________________________ адресы буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә. | |
| ________________________ адресы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кәгазьдә. | |
| ______________________ почта адресына кәгазь чыганакта җибәреп. | |
| Санап үтелгән ысулларның берсе күрсәтелә | |

___________________

(____________________________________________________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта))

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше
планын бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

кемгә:
(фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта) –
гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен,
оешманың тулы исеме – юридик затлар
өчен, почта индексы һәм адресы,
электрон почта адресы)

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул
итүдән баш тарту турында карар

Дата ________________________ №___________

____________________ (мөрәҗәгать итүче) _______________ №________ мөрәҗәгате нигезендә, _хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки (баш тарту нигезе):

________________________________________________________________________

Баш тарту сәбәбен дәлилле нигезләү: ________________________________________________

________________________________________________________________________

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ________________________________ (баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Документларны кабул итүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итүгә каршылык була алмый.

Әлеге баш тартуга карата, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

________________________________________________________________________

(карар кабул ителә торган органда вәкаләтле затның вазыйфасы
(имза, инициаллар)

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

кемгә:
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) – гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен, оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен, почта индексы һәм адресы, электрон почта адресы)

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

Дата ____________ №____________

____________________ (мөрәҗәгать итүче) _______________ №________ мөрәҗәгате нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки (баш тарту нигезе):
__________________________________________________________________________

Баш тарту сәбәбен дәлилле нигезләү:
__________________________________________________________________________

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ________________________________ (баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Күрсәтелгән хокук бозулар бетерелгәннән соң, сез җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга карата, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

__________________________________________________________________________
(карар кабул итүче органның вәкаләтле заты вазыйфасы (имзасы, инициаллары))

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

кемгә:
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) – гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен, оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен, почта индексы һәм адресы, электрон почта адресы)

Техник хатаны төзәтүдән баш тарту турында карар

Дата ____________ №____________

______________________________ (мөрәҗәгать итүче) _________________________ №____________ мөрәҗәгать нигезендә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планындагы техник хатаны төзәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, чөнки (баш тарту өчен нигез): ___________________________________________________________________________

Баш тарту сәбәбен дәлилле нигезләү: ___________________________________________________________________________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ______________________________ (баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат күрсәтелә).

Документларны кабул итүдән баш тарту дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап, кабат мөрәҗәгать итүгә каршылык була алмый.

Әлеге баш тартуга карата, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

___________________________________________________________________________
(карар кабул итүче органның вәкаләтле заты вазыйфасы (имзасы, инициаллары))